| ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>***БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ***<br>***БУА ШӘҺӘР СОВЕТЫ*** | РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>***БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН***<br>***БУИНСКИЙ ГОРОДСКОЙ СОВЕТ*** |
|---|---|

# КАРАР
# РЕШЕНИЕ

26 июнь 2023 ел № 2-32

Татарстан Республикасы Буа муниципаль
районы Буа шәһәре муниципаль
берәмлеге территориясендә төзекләндерү
кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге турында» 1999 елның 30 мартындагы 52-ФЗ номерлы, «Тирә-як мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясе тимер юл транспорты уставы» 2003 елның 10 гыйнварындагы 18-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә Буа шәһәр Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. «ТР Буа муниципаль районы Буа шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» Буа шәһәр Советының 2017елның 14 ноябрендәге 3-27 номерлы карары белән расланган (30.07.2020 № 2-59, 11.02.2021 № 9-7 карарлары редакциясендә) Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Буа шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү кагыйдәләренә (алга таба –Кагыйдәләр) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 50.11.пунктын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә язарга:

«50.11 коммуналь билгеләнештәге объектлар, инженерлык коммуникацияләре (корылмалар), юллар, күперләр, җәяүлеләр үтү урыннары төзелгәннән, реконструкцияләнгәннән һәм ремонтланганнан соң төзекләндерүнең бозылган элементларын торгызу, реставрация, археология һәм башка җир эшләре үткәрү;»;

1.2. 52 пунктны үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә язарга:

«52. Юл территорияләрен тоту үз эченә түбәндәгеләрне ала:

1) юлларны, тротуарларны, ясалма юл корылмаларын, квартал эчендәге юлларны ремонтлау;

2) тротуарлардан (йөртүче зоналарыннан, юллардан) һәм юлның йөрү өлешеннән, ясалма юл корылмаларыннан пычрак, чүп-чар, кар һәм боз (бозлык) җыю;

3) юл япмаларын юу һәм су сиптерү;

4) газоннар һәм яшел утыртмаларны карап тоту;

5) кече архитектура формаларын ремонтлау һәм буяу;

6) ясалма юл корылмалары составына керүче күзәтү һәм яңгыр суларын кабул итү коеларын, тау канауларын һәм ачык лотокларны төзү, ремонтлау һәм чистарту;

7) стеналарны, коймаларны, турникетларны, кечкенә архитектура формаларын төзү, ремонтлау һәм ел саен буяу.»;

1.3. 72.1 пунктын төшереп калддырырыга;

1.4. 72.2 пунктын 72.1 пункты дип санарага;

1.5. 72.3 пунктын 72.2 пункты дип санарага;

1.6. 82 пунктны үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә язарга:

«82. Тышкы яктырту багналары саклагыч, аергыч коймалар, юл корылмалары һәм юл җиһазлары элементлары буялырга, язулардан һәм теләсә нинди мәгълүмати-басма продукциядән чистартылырга, төзек хәлдә һәм чисталыкта тотылырга тиеш.»;

1.7. 83 пунктны үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә язарга:

«83. Тышкы яктырту баганаларын алыштырганда, күрсәтелгән конструкцияләр өч тәүлек эчендә сүтелергә һәм челтәр хуҗалары тарафыннан чыгарылырга тиеш.

Тышкы яктыртуның җимерелгән баганаларын чыгару юллардагы терәк хуҗасы тарафыннан шундук, калган территорияләрдә мондый ихтыяҗ ачыкланганнан соң (демонтажланганнан соң) бер тәүлек дәвамында башкарыла.»;

1.8. 84 пунктны үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә язарга:

«84. Барлык элементларның һәм объектларның төзек һәм куркынычсыз торышы һәм канәгатьләнерлек тышкы кыяфәте өчен милекче (хуҗа) җаваплы.».

2. «Буа муниципаль районы Буа шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» Буа шәһәр Советының 2017 елның 14 ноябрендәге 3-27 номерлы карары белән ( 30.07.2020 № 2-59, 11.02.2021 № 9-7 караралары редакциясендә) расланган Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Буа шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү кагыйдәләренең үзгәртелгән нигезләмәләренең яңа редакциясен хупларга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән законлы көченә керә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/, шулай ук Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru. адресы буенча урнаштырылырга тиеш.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Буа шәһәре башлыгы урынбасары С. А. Зайцевага йөкләргә.

Буа шәһәре башлыгы,
Совет рәисе Р.Р. Камартдинов